МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2026 ел № М 435

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 691 номерлы Карары үз көчен югалтуны тану турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2015 елның 2 февралендәге УП-71 номерлы Указы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2015 елның 14 гыйнварында «Челнинские известия» газетасының 1 нче санында бастырып чыгарылган Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 691 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев